**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 156-18 «26» июль 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 97-12 номерлы «Какре - Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе җирле үзидарәсен оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы белән, 2009 елның 2 декабрендәге 369-ФЗ номерлы «Җир асты байлыклары турында «Россия Федерациясе Законына авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, эзләү һәм чыгару өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салуны камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында», 2021 елның 30 апрелендәге 123-ФЗ номерлы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законнарны , «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законның 1 статьясын үтәү йөзеннән һәм Россия Федерациясе Югары Советының «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү тәртибе турында нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе хакында» карары һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләре» нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының 2021 елның 14 декабрендәге 97-12 номерлы «Какре - Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре» карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Кәкре Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. III өлештә. Шәһәр төзелеше регламентлары:

а) 22 статьяның 10 пунктында:

- икенче абзацта « геологик объектларның,» сүзләреннән соң «авыр чыгарыла торган файдалы казылмаларны геологик өйрәнү, разведкалау һәм чыгару технологияләрен эшләү,» сүзләрен өстәргә;

- дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан

нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яисә тыелырга мөмкин. Торак пунктлар һәм территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау куркынычы тудырырга, тау эшкәртмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларның сакланышын да кертеп, биналарның һәм корылмаларның сакланышын булдырырга мөмкин булган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин. Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла («Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 8 статьясы).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге  веб-адрес буенча бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай район Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин